**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 15 ноябрендәге 4711 номерлы карары**

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидияләр алуга шәһәр конкурсы турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясы, 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерцияле булмаган оешмалар турында»гы федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар җитештерүчеләргә, эшләр башкаручыларга, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлауларны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2022 елның 19 декабрендәге 3-19 номерлы «2023 елга һәм 2024, 2025 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 25 маендагы 2128 номерлы «2016-2025 елларга Казан шәһәрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль программасы турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Расларга:

1.1. Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидияләр алуга шәһәр

конкурсы турында нигезләмәне (1 номерлы кушымта);

1.2. террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидияләр алуга конкурс комиссиясе составын (2 номерлы кушымта).

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 19 июнендәге 1683 номерлы «Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2023 елда субсидия алуга шәһәр конкурсы турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 15 ноябрендәге
4711 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидияләр алуга шәһәр конкурсы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруны булдыра торган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү максатларын, шартларын, тәртибен, субсидияләр алуга конкурс уздыру тәртибен, шулай ук субсидияләр алучылар тарафыннан аларны бирү шартлары бозылган очракта аларны кире кайтару тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 2 пункты, 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерцияле булмаган оешмалар турында»гы федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар җитештерүчеләргә, эшләр башкаручыларга, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлауларны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә эшләнгән.

1.3. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга субсидияләр бирү максаты 2024 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүдән гыйбарәт.

1.4. Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны каплау өчен социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга субсидияләр бирү (алга таба – Субсидия) 2016-2025 елларга Казан шәһәрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыру кысаларында бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары чикләрендә 2024 елга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында шул максатларга расланган акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

1.5. Конкурсны «Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты» Муниципаль казна учреждениесенең Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлеге оештыра.

1.6. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирүгә каралган бюджет акчаларының төп бүлүчесе булып «Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты» Муниципаль казна учреждениесе (алга таба – вәкаләтле орган) тора.

1.7. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- конкурс – социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар арасында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны каплау өчен 2024 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр алу хокукына уздырыла торган конкурс процедуралары;

- социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма – 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерцияле булмаган оешмалар турында»гы федераль законда каралган формаларда төзелгән (дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән, сәяси партияләр булып торучы иҗтимагый берләшмәләрдән тыш) һәм гамәлгә кую документлары нигезендә 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерцияле булмаган оешмалар турында»гы федераль законның 31.1 статьясында саналган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра торган коммерцияле булмаган оешма;

- социаль әһәмияткә ия проект (алга таба шулай ук – проект) – социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманың гамәлгә кую документларына һәм 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерцияле булмаган оешмалар турында»гы федераль законның 31.1 статьясы белән каралган

эшчәнлек төрләренә туры килә торган конкрет бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән үзара бәйле чаралар комплексы;

- сайлап алуда катнашучы – конкурста катнашуга гариза биргән социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма;

- конкурста катнашучы – социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманың вәкаләтле органы дип танылган һәм конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гариза бирүче оешма;

- субсидия алучы – конкурста катнашырга рөхсәт ителгән һәм әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләргә туры килә торган гариза бирүче оешма;

- конкурс комиссиясе – конкурс уздыру чорына вәкаләтле орган тарафыннан төзелә торган субсидия бирү мәсьәләләрен карау буенча вакытлы коллегиаль орган.

1.8. Субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга түбәндәге юнәлешләр буенча чыгымнарны каплауга бирелә:

- мәдәни-мәгърифәтчелек һәм белем бирү чараларын оештыру;

- деструктив берләшмәләргә җәлеп итүне профилактикалау;

- матди-техник базаны яхшырту;

- экстремизм идеологиясенә буйсынган затларның социаль адаптациясе;

- проектларны гамәлгә ашыруга җәлеп ителгән затларны матди стимуллаштыру.

- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яши торган Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен яклау һәм үстерү.

1.9. Субсидия алуга чыгымнар составына 2024 елда (гариза бирелгән көнгә кадәр) террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга киткән түбәндәге чыгымнар керә:

- хезмәт өчен түләү;

- товарлар, эшләр, хезмәтләр өчен түләү;

- аренда түләвен башкару;

- Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр башкару.

1.10. Субсидия алу хокукына 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерцияле булмаган оешмалар турында»гы федераль законда билгеләнгән коммерцияле булмаган оешма категориясенә кертү

критерийларына туры килгән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып барган дәүләт яисә муниципаль учреждениеләр булмаган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар ия.

1.11. Социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр әлеге Нигезләмәгә таянып вәкаләтле орган уздыра торган конкурс нәтиҗәләре буенча бирелә.

1.12. Субсидия бирү турында белешмәләр Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында карар проектын формалаштырганда урнаштырыла.

## II. Субсидия бирү тәртибе һәм шартлары

2.1. Конкурс уздыру турында игълан Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) (алга таба – рәсми портал) яңалыклар бүлегендә https://kzn.ru/meriya/mezhvedomstvenye-komissii/antiterroristicheskaya-komissiya-/novosti/ урнаштырыла.

Игъланда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Интернет челтәрендә бюджет акчаларын төп бүлүченең рәсми порталында сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыру көне (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 7 пунктының икенче абзацы нигезендә);

- сайлап алуны уздыру вакыты;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта гаризаларны кабул итүнең тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннең 30 календарь көненнән иртәрәк була алмый;

- бюджет акчаларын төп бүлүченең яисә башка юридик затның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

- субсидия бирү өчен нигез булып торган эшчәнлек нәтиҗәсе (нәтиҗәләре), шулай ук нәтиҗәнең (аны билгеләгәндә) характеристикасы (характеристикалары);

- Интернет челтәрендә домен исеме;

- әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктчасы нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата билгеләнгән таләпләр, аларга сайлап алуда катнашучы

хокукый акт белән билгеләнгән көнгә һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә туры килергә тиеш;

- субсидия алучыларның категорияләре һәм бәяләү критерийлары, бәяләү критерийлары күрсәткечләре;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү тәртибе һәм гаризаларның формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

- гаризаларны кире алу тәртибе, аларны кире кайтару, шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгеләү тәртибе, гаризаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

- әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктчасы нигезендә гаризаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

- эшләп бетерүгә гаризаларны кире кайтару тәртибе;

- гаризаларны кире кагу тәртибе, шулай ук аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

- бәяләү критерийларын, бәяләү критерийлары күрсәткечләрен (кирәк очракта) үз эченә алган гаризаларны бәяләү тәртибе һәм гомуми бәяләүдә аларның әһәмияте, сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылырга тиешле бәяләүнең һәр критерие, бәяләү критерие күрсәткече (кирәк очракта) буенча мәгълүмат, мондый мәгълүматны раслый торган белешмәләр, документлар һәм материаллар, сайлап алуда катнашучыларга аларны сайлап алуда җиңүчеләр дип тану өчен гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре буенча җыярга кирәк булган минималь узу баллы (кирәк очракта), гаризаларны бәяләү вакыты, шулай ук гаризаларны бәяләүдә комиссиянең һәм экспертларның (эксперт оешмаларының) катнашуы яисә катнашмавы турында мәгълүмат (конкурс уздырылган очракта);

- сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидияләр күләме, хокукый актта билгеләнгән субсидияләр күләмен исәпләү тәртибе, җиңүчегә (җиңүчеләргә) бирелә торган субсидияләрнең максималь, минималь күләмен, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны үз эченә ала алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияләрне бүлү кагыйдәләре;

- сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү тәртибе, аңлатмалар бирүнең башлану һәм тәмамлану көне;

- сайлап алу җиңүчесе (җиңүчеләре) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан 2024 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар

өлешен каплауга субсидияләр бирү турындагы килешүне (алга таба – Килешү) имзаларга тиешле вакыт;

- сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) Килешү төзүдән баш тарткан (баш тартканнар) дип тану шартлары;

- сайлап алу нәтиҗәләрен ясау беркетмәсен (сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре турындагы документны) рәсми порталда урнаштыру вакыты, ул сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннән соң килгән 14 календарь көннән дә соң булырга тиеш түгел;

- хокукый акт белән билгеләнгән башка мәгълүмат (кирәк очракта).

2.2. Субсидия алучыга түбәндәге таләпләр куела:

- субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) чит ил юридик заты, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда, офшор компанияләренең акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган сатуларда әйләнештә йөри торган гавами акционерлык җәмгыятьләре (шул исәптән халыкара компания статусы булган) капиталында турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук башка Россия юридик затлары капиталында офшор компанияләренең, әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып, турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

- субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) экстремистик эшчәнлеккә яки терроризмга катнашлары турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) БМО Уставының VII бүлеге, БМО Куркынычсызлык советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында яки БМО Куркынычсызлык советы карарлары нигезендә махсус төзелгән оешмалар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) хокукый акт нигезендә, Россия Федерациясе субъектының башка норматив хокукый актларына,

муниципаль хокукый актларга таянып, хокукый актта билгеләнгән максатларга субсидия бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан (җирле бюджеттан), акчалар алмый;

- субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

- субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

- субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) Россия Федерациясе субъектының югары башкарма органы (җирле администрация) тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш хокукый акт нигезендә субсидия бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе субъекты бюджетына (җирле бюджетка) башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы, шулай ук хокукый акт нигезендә бюджетыннан субсидия бирү планлаштырыла торган гавами-хокукый берәмлек алдында акчалата йөкләмәләр буенча түләү вакыты узган (җайга салынмаган) бурычы юк;

- юридик зат булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) үзгәртеп оештыру (субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булып торган юридик затка башка юридик затны кушу формасында гамәлгә ашырылган үзгәртеп оештырудан тыш), ябылу процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган, ә шәхси эшмәкәр булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;

- дисквалификацияләнгән затлар реестрында юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яисә баш бухгалтеры (булган очракта) турында, шәхси эшмәкәр турында һәм субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булган товар җитештерүче, эш башкаручы, хезмәт күрсәтүче физик зат турында белешмәләр юк;

Субсидия алуга гариза биргән көнгә 2.2 пунктта күрсәтелгән таләпләр актуаль булырга тиеш.

2.3. Сайлап алуда катнашучы конкурс үткәрү турында игълан

урнаштырылган көннән соң килүче 30 календарь көн эчендә вәкаләтле органга түбәндәге документларны һәм материалларны тапшыра:

- субсидия алу максаты һәм күләме турында белешмәләрне, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә гариза бирүче оешма турында мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыкны, шулай ук оешма турында белешмәләрне (оешманың мәгълүмати картасы), проектны гамәлгә ашыруга сайлап алуда катнашучының фактта тотылган чыгымнарын раслый торган документларның күчермәләрен (килешүләр, башкарылган эшләр/хезмәт күрсәтүләр актлары, түләүгә счетлар, түләү йөкләмәләре, чеклар һәм контроль-касса техникасы турында белешмәләр һәм башка раслый торган документлар) дә кертеп, проект турында белешмәләрне (проектның мәгълүмати картасы) туплаган гариза. Гаризаның формасы әлеге Нигезләмәгә 1 номерлы кушымтада бирелгән, (аңа беркетелә торган документларның формалары – гаризага 1, 2, 3 номерлы кушымталарда);

- социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма уставының күчермәсе;

- әгәр күрсәтелгән документларга гариза бирүче оешма исеменнән аның гамәлгә кую документлары нигезендә ышанычнамәсез эш итәргә хокукы булмаган зат имза куйса (таныкласа), әлеге пунктта күрсәтелгән документларга имза кую (таныклау) өчен затның вәкаләтләрен раслый торган ышанычнамә яисә башка документ (алга таба – гариза бирүче оешманың ышанычнамәсе).

Сайлап алуда катнашучы үз инициативасы буенча түбәндәге документларны тапшыра:

- гариза бирүче оешманың законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычы булмавын раслый торган документ, шулай ук сайлап алуда катнашучының үзгәртеп кору, ябылу стадиясендә булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, конкурста катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булуын раслый торган документлар;

- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (документ коммерцияле булмаган оешма тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырыла яисә ведомствоара хезмәттәшлек барышында вәкаләтле орган белгече тарафыннан соратып алына).

2.4. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар кәгазь чыганакта бер нөсхәдә яисә электрон рәвештә тапшырыла һәм кире кайтарылмый.

Әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктчасында күрсәтелгән документлар тегелгән һәм номерланган булырга, җитәкченең имзасы һәм оешма мөһере белән таныкланган булырга тиеш.

Гариза шулай ук документларның электрон күчермәләре рәвешендә (сканерлау юлы белән электрон рәвешкә китерелгән кәгазь чыганактагы документлар) алга таба карау өчен төп нөсхәләрен тәкъдим итеп тапшырылырга мөмкин, аларны тапшыру сайлап алуны уздыру турында игъланда каралган. Документларның электрон күчермәләре конкурсны оештыручының электрон адресына (prof.kazan@tatar.ru) тапшырыла.

Сайлап алуда катнашучы, субсидия алу максатыннан тапшырылган документларның, документлардагы белешмәләрнең дөреслеге өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы.

2.5. Бер сайлап алуда катнашучы бер генә гариза бирергә хокуклы, ул конкурска тәкъдим ителә торган бер яисә берничә проект турында белешмәләрне туплаган була ала.

2.6. Конкурста катнашуга гаризаны кире кагу өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- сайлап алуда катнашучының әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктчасында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

- гариза бирүче оешма тарафыннан тапшырылган гаризаның һәм документларның әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктчасында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- гариза бирүче оешма тарафыннан тапшырылган мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турында мәгълүматның дөрес булмавы;

- гариза бирүче оешма тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктчасында билгеләнгән вакыт чикләреннән соң гариза бирү;

- гаризада күрсәтелгән субсидия алу максатының конкурсның өстенлекле юнәлешләренә туры килмәве.

2.7. Вәкаләтле орган белгече гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кабул итә, теркәлү журналында килгән гаризаны терки, оешма вәкиленә документларны кабул итү турында раслама бирә.

2.8. Вәкаләтле орган гаризалар кабул итү тәгәлләнгәннән соң ике эш көне эчендә гариза бирүче оешманы конкурста катнашучы дип тану максатыннан гаризаларны карап тикшерүне башкара.

Әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктчасында күрсәтелгән гаризаны кире кагу өчен нигезләр ачыкланган очракта, вәкаләтле орган гаризаларны кабул итү тәмамланганнан соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча кире кагу сәбәпләрен аңлатып, гаризаны кире кагу турында хат әзерли.

Гаризаны кире кагу турында әзерләнгән хат вәкаләтле орган җитәкчесе

тарафыннан имзалана һәм оешмага гаризада күрсәтелгән юридик адресы һәм (яисә) электрон почта адресы буенча җибәрелә.

2.9. Гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган конкурста катнашучыларның исемлеген төзи, ул Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында https://kzn.ru/meriya/mezhvedomstvenye-komissii/antiterroristicheskaya-komissiya-/munitsipalnaya-programma-profilaktiki-terrorizma-i-ekmistrezma-v-kazani-2016-2020-gody/ мәҗбүри рәвештә басылып чыгарга тиеш.

## III. Конкурс комиссиясе

3.1. Конкурс комиссиясе составы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана. Конкурс комиссиясе конкурс комиссиясе рәисеннән, конкурс комиссиясе рәисе урынбасарыннан, конкурс комиссиясе сәркатибеннән, конкурс комиссиясе әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясе әгъзалары саны так булырга һәм 5 (биш) кешедән дә ким булмаска тиеш.

Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары конкурс комиссиясе рәисе булмаган чорда аның вазифаларын башкара.

Конкурс комиссиясе сәркәтибе конкурс комиссиясе утырышының вакыты һәм урыны турында конкурс комиссиясе әгъзаларына хәбәр итә, конкурс комиссиясе утырышларының беркетмәләрен алып бара.

Әгәр конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының яртысыннан күбрәге катнашса, ул хокуклы булып тора.

Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Конкурс комиссиясе әгъзасы тавыш бирү хокукын башка затка тапшырырга хокуксыз.

Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Вәкиле конкурс комиссиясе әгъзасы булган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма конкурс катнашучысы була алмый.

Конкурс комиссиясе:

- конкурста катнашучылар тапшырган гаризаларны карап тикшерә;
- конкурс уздыру нәтиҗәләре турында карар кабул итә.

3.2. Конкурс комиссиясе әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымтада күрсәтелгән критерийлар буенча конкурста катнашучылар тарафыннан катнашуга тәкъдим ителгән гаризаларны карый.

3.3. Конкурс комиссиясе конкурста катнашучылар тарафыннан тәкъдим

ителгән гаризаларны алган көннән алып 2 календарь көн эчендә карый.

Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы һәр проектны аерым бәяли. Баллар тулы саннарда күрсәтелә һәм бәя бирү ведомостена куела, аның формасы әлеге Нигезләмәгә 3 номерлы кушымтада күрсәтелгән.

Конкурс комиссиясе сәркатибе, комиссия әгъзаларының бәяләү ведомостена таянып, әлеге Нигезләмәгә 4 номерлы кушымта нигезендә карап тикшерелә торган һәр проект буенча нәтиҗә ведомостен тутыра.

Һәр проектка бирелгән баллар нигезендә проектларның гомуми рейтингы, шулай ук конкурсның һәр өстенлекле юнәлеше буенча проектлар рейтингы формалаштырыла, иң күп баллар җыйган проектлар рейтингта иң югары урынны алып тора.

Баллары тигез санда булса, приоритетка түбәндәге проект ия була:

- иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрне башкаручы коммерцияле булмаган оешма статусына ия булган оешма тарафыннан бирелгән;

- «Сайланган өстенлекле юнәлеш өчен проект нәтиҗәләренең әһәмияте» гаризаларны бәяләү критерие буенча иң күп балл алган.

Конкурсның һәр өстенлекле юнәлеше буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының конкурс уздыру турындагы карары белән расланган санда проектлар исемлеге билгеләнә.

Конкурсның өстенлекле юнәлешләре буенча проектларны гамәлгә ашыруга субсидия суммасы Казан шәһәре Башкарма комитетының конкурс уздыру турындагы карары белән расланган санда билгеләгәннән соң, субсидия бирүгә юнәлдерелгән акчаларның бүленмичә калган өлеше булган очракта, гомуми рейтингта теге яисә бу өстенлекле юнәлешкә каравына бәйсез рәвештә иң югары урынны биләгән проектлар арасыннан өстәмә рәвештә проектлар сайлап алына.

Һәр проект өчен субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С=К \times З,$$ биредә:

С – субсидия күләме;

К – нәтиҗәлелек коэффициенты;

З – оешма сораган ярдәм суммасы.

Нәтиҗәлелек коэффициенты (К) түбәндәгечә исәпләнә:

$$К=Б:М,$$ биредә:

К – нәтиҗәлелек коэффициенты;

Б – бәяләү критерийлары нигезендә проектларга бирелгән баллар;

М – максималь мөмкин булган баллар саны.

3.4. Гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- субсидия бирү турында;

- субсидия бирүне кире кагу турында.

Комиссия утырышын уздырганнан соң өч эш көне эчендә комиссия карары утырышта катнашкан барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмәдә теркәлә.

Беркетмәгә имза куелган көннән соң ике эш көне эчендә комиссия сәркатибе оешма адресына субсидия бирү турында яисә субсидия бирүне кире кагу турында язмача хәбәрнамә җибәрә.

## IV. Субсидия күләме

Әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән критерийлар нигезендә, конкурста сайлап алуны уңышлы узган катнашучыларга түбәндәгеләр бирелә:

конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча 1 урын алган катнашучыга – 700,0 мең сум;

конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча 2 урын алган катнашучыга – 550,0 мең сум;

конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча 3 урын алган катнашучыга – 450,0 мең сум.

## V. Субсидия түләү тәртибе

5.1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар – субсидияләр алучылар исемлеге комиссия беркетмәсе белән раслана.

5.2. Вәкаләтле органның гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат беркетмәгә имза куелган көннән соң өч эш көне эчендә рәсми порталда урнаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

- гаризаларны карап тикшерү көнен, вакытын һәм урынын күрсәтү;

- гаризаларны бәяләү көнен, вакытын һәм урынын күрсәтү;

- гаризалары карап тикшерелгән конкурста катнашучылар турында белешмәләр;

- кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган конкурста

катнашучылар турында белешмәләр;

- гаризаларны бәяләү тәртибе, гаризаларны бәяләүнең каралган һәр критерие буенча гаризаларга бирелгән күрсәткечләр, гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән гаризаларга тәртип номерлары бирү турында карар;

- Килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

5.3. Субсидия бирү шартлары:

- субсидия алучының әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе;

- Казан шәһәре Башкарма комитеты белән субсидия алучы арасында Килешү төзү;

- субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең субсидия алучы тарафыннан үтәлешен вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органнары тикшерүенә субсидияләр алучының ризалыгы;

- Килешү нигезендә субсидия алучы тарафыннан хисап тапшыру.

5.4. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга субсидияләр террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар чыгымнары бәясенең 90 процентыннан артмаган күләмдә бирелә.

Субсидия күләме әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын төп бүлүчегә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары үзгәргән очракта үзгәрә.

5.5. Комиссия беркетмәсенә имза куелганнан һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган субсидияне алучы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар исемлеген раслаганнан соң ике эш көне эчендә конкурсны оештыручы Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе тарафыннан билгеләнгән форма буенча төзелгән Килешү проектын әзерли һәм Килешү проектының ике нөсхәсен субсидия алучыга җибәрә.

5.6. Килешүләр беркетмәгә имза куелган һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган субсидияне алучы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар исемлеген раслаган көннән соң ике эш көне эчендә төзелә.

Килешү әлеге пункт белән билгеләнгән вакытта ике нөсхәдә имзалана.

Вәкаләтле орган әлеге пунктта билгеләнгән вакытта субсидия алучы

тарафыннан имзаланган Килешү проектын алмаган очракта, вәкаләтле орган күрсәтелгән вакыт узганганнан соң ике эш көне эчендә субсидия алучыны Килешү төзүдән баш тарткан дип тану турында һәм субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул итә һәм субсидия алучыга кабул ителгән карар турында, кабул итү сәбәпләрен нигезләп, язмача хәбәрнамә җибәрә.

5.7. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманың әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вакытта килешү төзелмәве коммерцияле булмаган оешманың субсидия алудан берьяклы ирекле рәвештә баш тартуы булып тора.

5.8. Субсидияләр Килешүне имзалаганнан соң биш календарь көн эчендә субсидия алучы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның исәп-хисап счетларына күчерелә.

5.9. Субсидия күләме үзгәргән очракта, вәкаләтле орган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма белән өстәмә килешү төзи.

## VI. Хисап бирүгә таләпләр

6.1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар конкурсны оештыручыга Килешү нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында мәгълүмати хисап тапшыралар.

## VII. Субсидия бирү шартларын, тәртибен үтәүне контрольдә тотуга таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

Субсидия бирү шартларын, тәртибен үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыруга һәм аларны бозган өчен җаваплылыкка карата таләпләр вәкаләтле орган тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268 һәм 269 статьялары нигезендә дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр гамәлгә ашырылуын тикшерүгә таләпне кертәләр.

## VIII. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның грантлар бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәгән өчен җаваплылыгы

Бюджет акчаларын баш бүлүче һәм муниципаль финанс контроле

органнары тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, шул исәптән субсидияне максатчан файдаланмау фактын, шулай ук субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр бирү фактын бозу ачыкланганда, субсидия тулы күләмдә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тиешле таләпләрне алган көннән алып 10 календарь көн эчендә.

Субсидия күрсәтелгән вакытта кире кайтарылмаган очракта, вәкаләтле орган суд тәртибендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кайтарылырга тиешле субсидияне алу чараларын күрә.

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 15 ноябрендәге
4711 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидия алуга конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Б.Р.Алиев | конкурс комиссиясе рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе |
| В.И.Яковлев | конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары – хокук идарәсе башлыгы |
| Р.Ә.Мөхәрьямов | конкурс комиссиясе сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны кисәтү өлкәсендәге программаларны координацияләү бүлегенең баш белгече. |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Л.Н.Замова | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлеге башлыгы |
| Р.Ә.Мөхәрьямов | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны кисәтү өлкәсендәге программаларны координацияләү бүлеге башлыгы урынбасары – Казан шәһәрендә террорчылыкка каршы көрәш комиссиясе сәркатибе; |

| | |
|---|---|
| И.Р.Мөхәммәтшин | Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе башлыгы |
| И.Н.Сарманов | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы вазифаларын башкаручы |
| Е.С.Ямбаршева | «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе директоры |

---

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидия алуга шәһәр конкурсы турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

(Оешма бланкында рәсмиләштерелә)

**Конкурста катнашуга**
**гариза**

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны каплауга 2024 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидия алу хокукына социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар арасында конкурста катнашу өчен ______________________________________________________
(оешма атамасы)
гаризасын карауны сорыйм

Гариза бирү көненә оешма ябылу яисә үзгәртеп кору процессында булмавына, шулай ук вәкаләтле органның оешма эшчәнлеген туктатып тору турында гамәлдәге карары булмавына гарантия бирәм.

Кушымталар:
1. Оешманың ___ битлек ___ нөсхәдәге мәгълүмати картасы.
2. Проектның/проектларның ___ битлек ___ нөсхәдәге мәгълүмати картасы/мәгълүмати карталары.
3. Сайлап алуда катнашучының проектны гамәлгә ашыруга фактта тотылган чыгымнарын раслый торган документларның ___ битлек ___ нөсхәдәге күчермәләре.
4. Оешма уставының ___ битлек ___ нөсхәдәге таныкланган күчермәсе.
5. Оешма җитәкчесенең вәкаләтләрен раслаучы документлар.
6. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.
7. Салым органыннан соңгы хисап датасына оешманың барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлар һәм бюджеттан тыш фондлар алдында түләү вакыты узган бурычы булмавын раслый торган белешмә.
8. Электрон чыганакта (диск, флеш-карта) гаризаның күчермәсе.

| ______________________________ | ______________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (оешма җитәкчесе вазифасының атамасы) | (имза) | (Инициаллар һәм фамилия) |

Мөһер урыны

____________________
(дата)

Конкурста катнашуга гаризага
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Оешманың мәгълүмати картасы**

| | |
|---|---|
| 1. Оешманың тулы исеме | |
| 2. Оешманың кыскартылган исеме | |
| 3. Тәкъдим ителгән проектның исеме (тәкъдим ителгән проектлар исемлеге) | |
| 4. Оешманың оештыру-хокукый формасы | |
| 5. Оешманың реквизитлары | - |
| Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| Салым түләүченең тәнгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| Исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД) | |
| 6. Җәмәгать файдалы хезмәт күрсәтүләрен башкаручы итеп оешманың реестр номеры һәм аны тану датасы (оешма коммерцияле булмаган оешма - иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрне башкаручы статусына ия булса) | |
| 7. Элемтә өчен мәгълүмат | - |
| юридик адрес (почта индексы белән) | |
| телефон (торак пункт коды белән) | |
| электрон почта | |
| веб-сайт (булган очракта) | |
| 8. Оешманың банк реквизитлары | - |
| банкның атамасы | |
| банкның урнашу урыны (почта индексы белән) | |
| Банкның тәнгәлләштерү номеры (ИНН)/исәпкә кую сәбәбе коды КПП | |
| корреспондент счеты | |
| Банкның тәнгәлләштерү коды (БКК) | |
| исәп-хисап счеты | |
| 9. Оешма җитәкчесе | - |
| фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| җитәкче вазифасы (устав нигезендә) | |
| 10. Устав нигезендә оешма эшчәнлегенең төп максатлары (өчтән дә артык түгел) | |
| 11. Оешма эшчәнлеге юнәлдерелгән төп максатчан төркемнәр (өчтән дә артык түгел) | |
| 12. Соңгы ике елда алынган муниципаль субсидияләр турында белешмәләр (субсидия алу елы, субсидия | |

| | |
|---|---|
| суммасы, проектның исеме) | |
| 13. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, коммерциячел һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе | |
| 14. Соңгы ике елда уңышлы гамәлгә ашырылган өчтән дә артмаган проектларның кыскача тасвирламасы (проектның исемен, төп максатларны, проектның бюджетын, финанслау чыганакларын, ирешелгән нәтиҗәләрне күрсәтергә) | |
| 15. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (бастырылган материалга сылтамаларны күрсәтергә), массакүләм мәгълүмат чараларында (массакүләм мәгълүмат чарасын һәм материалның басмага, эфирга чыгу вакытын күрсәтергә) оешманың эшчәнлеге турында мәгълүмат булу | |

| ______________________ | ____________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (оешма җитәкчесе вазифасының атамасы) | (имза) | (Инициаллар һәм фамилия) |

Мөһер урыны

______________________
(дата)

Конкурста катнашуга гаризага
2 номерлы кушымта
(Форма)

**Проектның мәгълүмати картасы**

1. Грант соратыла торган проектның исеме
______________________________________________________________________.

2. Проект җитәкчесе (фамилиясе, исеме, атасының исеме, телефон)
____________________________________________________________.

3. Тәкъдим ителгән проект (Казан шәһәре Башкарма комитетының конкурс уздыру, өстенлекле юнәлешләрнең исемлеген һәм конкурс комиссиясе составын раслау турындагы карары нигезендә) гамәлгә ашырылачак өстенлекле юнәлеш

________________________________________________________________________

4. Проектның максатчан төркемнәре (проект юнәлтелгән максатчан төркемнәрнең астына сызарга):

| | | |
|---|---|---|
| - балалар һәм яшүсмерләр | - яшьләр һәм студентлар | - хатын-кызлар |
| - күп балалы гаиләләр | - ятимнәр | - мигрантлар |
| - пенсионерлар | - ветераннар | - сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләр |

- башка: ______________________________________
(билгеләргә)
__________________________________________________

5. Максатчан аудиторияне колачлау (проектта катнашучыларның якынча саны)

________________________________________________________________________

6. Проектның социаль әһәмиятен нигезләү (бер биттән артык түгел)
______________________________________________________________________

7. Проектның төп максатлары һәм бурычлары (ике биттән артык түгел)____________________________________________________________

8. Проектның тасвирламасы (ике биттән артык түгел)

________________________________________________________________________

9. Проектны гамәлгә ашыру чоры
_____________________________________________________________________

10. Проектны гамәлгә ашыру планы ________________________________

11. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә ирешү көтелә торган социаль нәтиҗә (сыйфат һәм (яисә) сан күрсәткечләре; социаль проблемаларны хәл итүгә кертелгән конкрет өлеш)

________________________________________________________________________

_______________________________________________

12. Проектны мәгълүмати яктан тәэмин итү

13. Проектны финанслау:_____________________________________

13.1. соратыла торган сумма (сумнарда) ____________________________

13.2. гариза бирүче оешманың үз акчаларын да кертеп, финанслауда катнашу (сумнарда) ________________________________________

13.3. Проектны гамәлгә ашыруның тулы бәясе (сумнарда) _____________

| ______________________________ | ______________ | _______________________ |
|---|---|---|
| (оешма җитәкчесе вазифасының атамасы) | (имза) | (Инициаллар һәм фамилия) |

Мөһер урыны

Конкурста катнашуга гаризага
3 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидия хисабына**

______________________________________________________________
(проектның исеме)
проектны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өлешен каплауга
**СУБСИДИЯЛӘР КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘҮ**

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектының тулы исеме: ________________________________
____________________________________________________________________________,
ИНН _______________, ОГРН ____________, КПП ____________, р/сч. ________,
банк исеме ________________________________________, БИК __________________,
корреспондент счеты ___________________________________
Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД) буенча оешма эшчәнлегенең төре ______________________________________________

| **Чыгымнар исеме** | **Нигезләгән документның реквизитлары** | **Хезмәтнең, товарның бәясе, сум** | **шул исәптән** | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **Субсидия акчалары хисабына, сум*** | **Үз акчалары хисабына, сум** |
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** |
| | | | | |
| БАРЛЫГЫ: | | | | |

___________________________________ ___________________ /_______________________/
[җитәкче вазифасы атамасы (булган очракта) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Баш бухгалтер ___________________ /_______________________/
(булган очракта) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Исәпләү тикшерелде 20___ елның «___» ___________

___________________________________ ___________________ /_______________________/
(хезмәткәрнең вазифасы атамасы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

20___ елның «___» ___________

Кушымталар: (чыгымнарны нигезләгән документларның таныкланган күчермәләре):
1...
2...

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидия алуга шәһәр конкурсы турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта

**Конкурста катнашуга тәкъдим ителгән гаризаларны бәяләү критерийлары**

1. Сайлап алынган өстенлекле юнәлеш өчен проект нәтиҗәләренең әһәмияте:

- проект әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;
- проект әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;
- проект әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;
- проект әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл;

2. Максатчан аудиторияне колачлау:

- 100 кешегә кадәр – 0 балл;
- 101 кешедән 500 кешегә кадәр – 2 балл;
- 501 кешедән 1000 кешегә кадәр – 4 балл;
- 1000 кешедән артык – 6 балл.

3. Бурычларны хәл итү өчен ысуллар һәм инструментлар сайлап алу дөреслеге:

- проект әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;
- проект әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;
- проект әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;
- проект әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл;

4. Проектның мәгълүмати яктан тәэмин ителү дәрәҗәсе:

- юк - 0 балл;
- түбән – 2 балл;
- уртача – 4 балл;
- югары – 6 балл.

5. Проектны гамәлгә ашыруга чыгымнарның гомуми суммасында башка чыганакларның проектны финанслауда катнашу өлеше:

- 10 проценттан 15 процентка кадәр – 0 балл;
- 16 проценттан 25 процентка кадәр – 2 балл;

- 26 проценттан 35 процентка кадәр – 4 балл;

- 36 процент һәм аннан да артык – 6 балл.

6. Конкурста катнашучының проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле тәҗрибәсе булу:

- әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;

- әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;

- әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;

- әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл;

7. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында конкурста катнашучының әһәмияткә ия эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүмат булу:

- әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;

- әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;

- әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;

- әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл;

8. Конкурста катнашучының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек тәҗрибәсе булу

- әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;

- әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;

- әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;

- әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл;

Максималь мөмкин булган баллар саны – 48.

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидия алуга шәһәр конкурсы турында нигезләмәгә
3 номерлы кушымта
(Форма)

***______ номерлы ________________________________________________________**
(проектның исеме)
**гариза тәкъдим иткән конкурс катнашучысын _________________________________**
(оешманың атамасы)

**бәяләү ведомосте**

| **Критерий атамасы** | **Балларда бәяләү вариантлары** | **Балларда бәяләү** |
|---|---|---|
| 1. Сайлап алынган өстенлекле юнәлеш өчен проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләренең әһәмияте | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 2. Максатчан аудиторияне колачлау | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 3. Бурычларны хәл итү өчен ысуллар һәм инструментлар сайлап алу дөреслеге | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 4. Проектның мәгълүмати яктан тәэмин ителү дәрәҗәсе | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 5. Проектны гамәлгә ашыруга чыгымнарның гомуми суммасында башка чыганакларның проектны финанслауда катнашу өлеше | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 6. Конкурста катнашучының проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле тәҗрибәсе булу | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 7. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында конкурста катнашучының әһәмияткә ия эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүмат булу | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 8. Конкурста катнашучының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар | 0 - 2 - 4 - 6 | |

| **Критерий атамасы** | **Балларда бәяләү вариантлары** | **Балларда бәяләү** |
| --- | --- | --- |
| белән үзара хезмәттәшлек тәҗрибәсе булу | | |
| Балларның гомуми суммасы | | |

Конкурс комиссиясе әгъзасы _______________ (имза) ______________________________ (имзаның аңлатмасы)

-----------------------------

*Гариза номеры гаризалар журналындагы номер нигезендә билгеләнә.

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерцияле булмаган оешмалар өчен 2024 елда субсидия алуга шәһәр конкурсы турында нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(Форма)

**________*номерлы ________________________________________________**

(проектның исеме)

_______________________________________________________________

(оешманың атамасы)

**гаризаны гомуми бәяләү ведомосте**

| **Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Балларда бәяләү** |
|---|---|
| | |
| | |
| Проект буенча балларның гомуми суммасы | |

Конкурс комиссиясе сәркатибе ______________ (имза) ______________________________ (имзаның аңлатмасы)

----------------------------

*Гариза номеры гаризалар журналындагы номер нигезендә билгеләнә.